ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.04.2021 г.Лениногорск № 429

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетында муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» яңа редакциядә» 2019 елның 08 августындагы 1112 номерлы карары белән расланган Кредит акчаларын кулланып торак сатып алуга алдан рөхсәт бирү һәм аны балигъ булмаганнар катнашында залогка (ипотекага) тапшыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Норматив-хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетында муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» яңа редакциядә» 2019 елның 08 августындагы 1112 номерлы карары белән расланган Кредит акчаларын кулланып торак сатып алуга алдан рөхсәт бирү һәм аны балигъ булмаганнар катнашында залогка (ипотекага) тапшыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.6 пунктта (хакимият органнары карамагында булган мәгълүмат):

«йорт (фатир) кенәгәсеннән өземтә» сүзләрен «яшәү урыны буенча теркәү турында мәгълүматлар – Россия Эчке эшләр министрлыгы» сүзләренә алыштырырга;

2.5. пунктта түбәндәге эчтәлектәге «3» пунтча өстәргә:

«3» пунктча 14 яшькә җитмәгән мөрәҗәгать итүче гаиләсенең барлык әгъзалары өчен бала туу турында таныклык – гражданлык хәле актларын теркәү органнары;

2. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотучы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары В.В. Друкка йөкләргә.

Җитәкче З.Г.Михайлова

И.Р.Хәйбрахманов
5-44-72